**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» Указына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2010 елның 24 декабрендәге ПУ-856 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 29 декабрендәге ПУ-892 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1210 номерлы, 2015 елның 9 октябрендәге ПУ-979 номерлы, 2016 елның 30 маендагы ПУ-487 номерлы, 2017 елның 21 апрелендәге ПУ-325 номерлы, 2018 елның 13 гыйнварындагы ПУ-30 номерлы, 2018 елның 8 маендагы ПУ-361 номерлы, 2018 елның 24 ноябрендәге ПУ-796 номерлы һәм 2021 елның 15 маендагы 383 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм:**»;

б) 2 пунктта «алты» сүзен «җиде» сүзенә алмаштырырга;

в) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасын кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 25 сентябрь
№ 791

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның « 25 » сентябрендәге
791 номерлы Указына
кушымта

# Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы структурасы

**Министр**

- Муниципаль районнарда, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге районнарында территориаль органнар
- Министр ярдәмчесе

**Министрның беренче урынбасары**
- Хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге
- Координацияләү һәм контроль бүлеге
- Хезмәтне саклауга дәүләт идарәсе бүлеге
- Тармак программаларын үстерү һәм эшләү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Контроль-ревизия эше бүлеге
- Планлаштыру, финанслау һәм хезмәткә түләү бүлеге
- Дәүләт сатып алулары бүлеге

**Министр урынбасары**
- Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге
- Социаль регистрны формалаштыру бүлеге
- Социаль ярдәм чаралары аудиты бүлеге
- Пенсиягә өстәмә түләү һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү һәм түләү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Эш белән тәэмин итүдә актив сәясәт чараларын гамәлгә ашыру бүлеге
- Хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән хезмәттәшлек итү бүлеге
- Хезмәт базарын анализлау һәм фаразлау, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне мониторинглау бүлеге
- Һөнәри белем һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Социаль хезмәт күрсәтү системасын оештыру бүлеге
- Социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге
- Социаль хезмәт күрсәтү сыйфатына идарә бүлеге
- Чаралар үткәрүне оештыру бүлеге

**Министр урынбасары**
- Тормыш эшчәнлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларны социаль интеграцияләү бүлеге
- Мәгълүмат технологияләре, техник хезмәт күрсәтү һәм автоматлаштырылган системаларны эксплуатацияләү, мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге
- Җир, мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм матди-техник тәэмин итү бүлеге

**Министр урынбасары**
- Махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль гарантияләрен үтәү бүлеге
- Иҗтимагый оешмалар белән эшләү бүлеге
- Халык белән эшләү секторы

**Эшләр идарәчесе**
- Эш башкару бүлеге
- Админис-тратив-хуҗалык бүлеге

**Юридик бүлек**
- Бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге
- Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге
- Мобилизация әзерлеге, граждан оборонасы секторы
- Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлеге

---